| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«9» декабрь, 2020 ел Олы Кайбыч ав. № 29

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 238 номерлы «Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советының 2020 елның 15 июнендәге 238 номерлы «Аренда түләүләрен түләүне кичектереп тору өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» карарына (2020 елның 31 августындагы 253 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Аренда түләүләрен түләүне кичектерү арендаторларга - кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшкуарлык субъектларына, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга - коммерциячел булмаган оешмалар реестрына кертелгән иҗтимагый файдалы хезмәтләр башкаручыларга бирелә дип билгеләргә.»;

2.1. пунктында «Башкарма хакимият органнарына, шулай ук дәүләт предприятиеләренә һәм дәүләт учреждениеләренә» сүзләрен «Кайбыч муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, шулай ук муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Совет Рәисе А.И.Рәхмәтуллин